| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июль 2024ел № 110

**Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Балтач шәһәр җирлеге Советы:

1. Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач шәһәр җирлеге Советының «Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»10.11.2021 ел, № 44 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башлыгына йөкләргә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин